ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.03.2019 Алексеевск ш.т.б. № 104

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында 2019 елга балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында**

Балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, 2019 елда мәктәп укучыларының һәм студентларның каникуллары вакытындагы мәшгульлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2018 елның 4 сентябрендәге 748 номерлы карары, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2021 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен, физик культура һәм спортны үстерү «Дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 7 февралендәге 73 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә

**карар бирәм:**

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында 2019 елга балалар һәм яшьләрнең ял итү программасын (1 номерлы кушымта);
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында нигезләмә (2 номерлы кушымта);
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район комиссиясе турында нигезләмә (3 номерлы кушымта);
- Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район комиссиясе составы (4 номерлы кушымта).

2. Финанс-бюджет палатасы рәисенә (Леденцов О. Н.) 2019 елга Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итүе, аларны савыктыру һәм эш белән тәэмин итү программасы нигезендә финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Н.П. Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
04.03.2019 № 104
карарына 1 номерлы кушымта

**2018 ЕЛГА АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНДА БАЛАЛАРҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫ, АЛАРНЫ САВЫКТЫРУ ҺӘМ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ПРОГРАММАСЫ**

ПРОГРАММАНЫҢ ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2019 елга Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялы, аларны савыктыру һәм эш белән тәэмин итү программасы (алга таба – Программа) |
| Муниципаль заказчы | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаны тормышка ашыручылар | - «ТР Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ;<br>- Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге;<br>- Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССУ;<br>- Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге;<br>- Алексеевск муниципаль районының «Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДБУ;<br>- Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге;<br>- Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Чистай, Спас, Алексеевск һәм Яңа Чишмә районнарындагы территориаль бүлеге;<br>- 104-ПЧС ФГКУ «ТР буенча 7 нче ФПС отряды»;<br>-Татарстан Республикасының Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнары буенча Районара бүлек УНД һәм Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе;<br>- Алексеевск муниципаль районының «Балалар яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр станциясе» өстәмә белем бирүче МБУ;<br>- Алексеевск муниципаль районының «Балалар иҗаты үзәге» өстәмә белем бирүче МБУ;<br>- «Татмедиа» ААҖ филиалы Алексеевск районының «Заря» («Таң») газетасы. |
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Балаларны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, сәламәтләндерүне арттыру; |

| | |
|---|---|
| | каникул чорында балаларны һәм яшьләрне ял белән тәэмин итү;<br>балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмаларына ярдәм;<br>балаларның тормыш-көнкүрешен яхшырту һәм имин булмаган проблемаларын хәл итү;<br>ятим балаларга, ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга, шулай ук инвалид балаларга, хроник авырулардан интегүче балаларга дәүләт ярдәме күрсәтү;<br>балаларның һәм яшьләрнең төрле ял итү формаларын, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү;<br>балалар һәм яшьләрне ял итү һәм сәламәтләндерү инфраструктурасын саклау һәм ныгыту;<br>балалар арасында авыруларны һәм инвалидлыкны профилактикалау;<br>авыр тормыш хәлендә булган балалар җәмгыяте белән нәтиҗәле комплекслы социаль яклау һәм интеграция формалаштыру;<br>балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;<br>ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны тәрбиягә алган гаиләләргә дәүләт ярдәме күрсәтү. |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2019 ел |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Белем бирү оешмаларындагы көндезге лагерьларда ял һәм сәламәтләндерү сменалары оештыру.<br>2. Хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыру.<br>3. Палатка тибындагы лагерьларда профильле сменалар оештыру.<br>4. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерь сменаларны оештыру.<br>5. Шәһәр читендәге ял лагерьларында профильле сменаларда катнашуны тәэмин итү. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2019 елга Программаны финанслауның гомуми күләме **18922597,93** сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруга субсидияләр – **18332180,33** сум;<br>Балалар һәм яшьләрнең ялын тәэмин итүгә субсидияләр – 0,0 сум;<br>Ата- аналар акчасы – **590417,6** сум. |
| Программаны тормышка ашыруның | Каникул вакытында балаларның ялын төрле формалар белән тәэмин итү 7-18 яшьлек балаларның гомуми санынннан 50 проценттан да ким түгел. |

| | |
|---|---|
| көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Ял итү сыйфатын һәм сәламәтләндерү дәрәҗәсен күтәрү, барлык программа чаралары буенча да чагылдырылган сәламәтләндерү нәтиҗәлелегенң 90 проценттан да ким булмаган күләмдә ирешү. |

## ӘЛЕГЕ ПРОГРАММА КЫСАЛАРЫНДА РАСЛАНГАН ХЕЗМӘТЛӘР КҮЛӘМЕ НОРМАТИВЛАРЫ НИГЕЗЕНДӘ ҮТКӘРЕЛӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР

| № | Чараның исеме | Үткәрү вакыты | Кешеләр саны | Оештыру өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Белем бирү оешмаларындагы көндезге ял һәм сәламәтләндерү лагерьларда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру | июнь<br>октябрь-ноябрь | 424<br>285 | «Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 2. | Хезмәт һәм ял лагерьларында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру | июнь | 270 | «Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| 3. | Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен палатка тибындагы лагерьларда профильле сменада оештыру | июнь-август | 2380 (7 көн) | «Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ<br>Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге |
| 4 | Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре балалары өчен стационар лагерьларда сменаларны оештыру | июнь-август | 60 | «Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| | **Барлыгы** | | **3419** | |

## БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАСЫ ОЕШТЫРГАН КӨНДЕЗГЕ ЯЛ ЛАГЕРЬЛАРДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Кешеләр саны | Көннәр саны | Юлламаның норматив бәясе (сум) | Бюджеттан бирелгән субсидияләр (сум.) | Ата-аналар түләве (сум.) |
|---|---|---|---|---|---|
| Җәйге чорда (ата-аналар түләве – 518 сум.) | | | | | |
| «1 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 75 | 21 | 3450,3 | 219964,50 | 38850,00 |
| «2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 100 | 21 | 3450,3 | 293286,00 | 51800,00 |
| 3 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 25 | 21 | 3450,3 | 73321,50 | 12950,00 |
| «4 нче Алексеевск башлангыч белем бирү мәктәбе » МКУ | 40 | 21 | 3450,3 | 117314,40 | 20720,00 |
| «Биләр урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 50 | 21 | 3450,3 | 146643,00 | 25900,00 |
| Кызыл Баран төп гомуми белем бирү мәктәбе МКУ | 20 | 21 | 3450,3 | 58657,20 | 10360,00 |
| Олы Тигәнәле төп гомуми белем бирү мәктәбе МКУ | 19 | 21 | 3450,3 | 55724,34 | 9842,00 |
| Урта Тигәнәле урта гомуми белем бирү мәктәбе МКУ | 20 | 21 | 3450,3 | 58657,20 | 10360,00 |
| «Сахаровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 20 | 21 | 3450,3 | 58657,20 | 10360,00 |
| «Ромодан урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 25 | 21 | 3450,3 | 73321,50 | 12950,00 |
| «Кыр Шунталысы төп гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 15 | 21 | 3450,3 | 43992,90 | 7770,00 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Речное төп гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 15 | 21 | 3450,3 | 43992,90 | 7770,00 |
| 12 | **424** | **21** | 3450,3 | 1243532,64 | 219632,00 |
| Калган чорда (ата-аналар түләве – 173 сум.) | | | | | |
| «1 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 65 | 7 | 1150,1 | 63545,3 | 11245 |
| «2 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 65 | 7 | 1150,1 | 63545,3 | 11245 |
| 3 нче Алексеевск урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 60 | 7 | 1150,1 | 58657,2 | 10380 |
| «4 нче Алексеевск башлангыч белем бирү мәктәбе » МКУ | 40 | 7 | 1150,1 | 39104,8 | 6920 |
| «Биләр урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 55 | 7 | 1150,1 | 53769,1 | 9515 |
| **5** | **285** | **7** | 1150,1 | 278621,7 | 49305 |

## ХЕЗМӘТ ҺӘМ ЯЛ ЛАГЕРЬЛАРЫНДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ
(ата-аналардан түләү алынмый)

| Лагерьны оештыру өчен база (мәктәп) | Кешеләр саны | Көннәр саны | Юлламаның норматив бәясе (сум) | Бюджеттан бирелгән субсидияләр (сум.) | Ата-аналар түләве (сум.) |
|---|---|---|---|---|---|
| «Зур Алан урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 20 | 18 | 2957,4 | 59148 | 0,00 |
| «Родники урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 25 | 18 | 2957,4 | 73935 | 0,00 |
| «Кыркүл урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 25 | 18 | 2957,4 | 73935 | 0,00 |
| «Зирекле урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 22 | 18 | 2957,4 | 65062,8 | 0,00 |
| «Левашово урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 22 | 18 | 2957,4 | 65062,8 | 0,00 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «Шәмә төп гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 20 | 18 | 2957,4 | 59148 | 0,00 |
| «Биләр урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 25 | 18 | 2957,4 | 73935 | 0,00 |
| «Лебедино урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 22 | 18 | 2957,4 | 65062,8 | 0,00 |
| «Ялкын урта гомуми белем бирү мәктәбе» МКУ | 22 | 18 | 2957,4 | 65062,8 | 0,00 |
| Чуаш Майнасы төп гомуми белем бирү мәктәбе МКУ | 22 | 18 | 2957,4 | 65062,8 | 0,00 |
| Юеш Көрнәле урта гомуми белем бирү мәктәбе МКУ | 45 | 18 | 2957,4 | 133083 | 0,00 |
| **11** | **270** | **18** | 2957,4 | 798498 | 0,00 |

ПАЛАТКА ТИБЫНДАГЫ ЛАГЕРЬЛАРДА ПРОФИЛЬЛЕ СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ

(«Сәләт» слетын оештырган өчен ата-аналардан түләү алынмый, «Олимп лагере өчен – 968 сум.)

| Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру формасы | Кешеләр саны | Көннәр саны | Юлламаның норматив бәясе (сум) | Бюджеттан бирелгән субсидияләр (сум.) | Ата-аналар түләве (сум.) |
|---|---|---|---|---|---|
| «Сәләт» балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары слеты | 2200 | 7 | 6450,15 | 14190330 | 0,00 |
| «Олимп» палатка тибындагы лагерьда профильле смена | 180 | 7 | 6450,15 | 986787 | 174240 |
| **БАРЛЫГЫ** | **2380** | 7 | | **15177117,6** | **15351357** |

## МУНИЦИПАЛЬҺӘМ ДӘҮЛӘТ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРЕ БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН СТАЦИОНАР ЛАГЕРЬЛАРДА СМЕНАЛАР ОЕШТЫРУ (Ата-аналар түләе 2454 сум 01 тиен)

| Стационар балалар сәламәтләндерү лагеренең исеме | Кешеләр саны | Көннәр саны | Юлламаның норматив бәясе (сум) | Бюджеттан бирелгән субсидияләр (сум.) | Ата-аналар түләве (сум.) | Башка акчалар | Барлыгы (сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балалары өчен стационар лагерь | 60 | 21 | 16360,05 | 834362,4 | 147240,6 | 0 | 981603 |

БАЛАЛАР ҺӘМ ЯШЬЛӘРНЕҢ ЯЛЫН ТӘЭМИН ИТҮГӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫ АКЧАЛАРЫ ИСӘБЕННӘН СУБСИДИЯЛӘР

| Күрсәткечнең атамасы | Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган субсидияләр суммасы, мең сум. |
|---|---|
| Муниципаль районның дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләре һәм хуҗалык итүче субъектлар (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) хезмәткәрләре арасыннан бер балага Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыруны тәэмин итүгә финанс чыгымнары нормативы | 0,0 |

**Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче** **Г.А.Юсупова**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
04.03.2019 № 104
карарына 2 номерлы кушымта

**Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру механизмын һәм Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының, җирле үзидарә органнарының, муниципаль, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләрнең, районда балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы оешмаларның һәм гражданнарның үзара хезмәттәшлеге тәртибен билгели.

1.2. Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча вәкаләтле орган булып балалар һәм яшьләрнең ялын оештыручы район комиссиясе тора. Балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район комиссиясе эшчәнлеге тәртибе һәм составы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.3. Әлеге нигезләмә кысаларында балалар һәм яшьләр ялы өчен шәхеснең белем бирү һәм иҗат потенциалын үстерү, сәламәтлекне саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау, организмны чыныктыру, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыру, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, иҗтимагый файдалы һәм җитештерү хезмәте, физик культура, спорт, туризм белән шөгыльләнүне, өлешчә яки тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы хисабына финанслана торган шартлар һәм чаралар комплексы аңлашыла.

2. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру формалары

2.1. Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:
шәһәр читендәге ял лагерында (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре балалары өчен стационар лагерьда) смена;
палатка тибындагы лагерьда профильле смена;
шәһәр яны ял лагерында профиль смена;
белем бирү оешмасы оештырган көндезге ял лагеренда смена;
ял һәм хезмәт лагеренда смена.

2.2. Шәһәр яны ял лагерындагы смена – каникуллар вакытында тәүлек буе балалар һәм тәрбияләнүчеләр белән стационар базада үткәрелә торган белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлегенең формасы. Җәйге каникулларда

сменаның озынлыгы 21 көннән дә ким булмаска тиеш, көзге, кышкы һәм язгы каникулларда – 7 көннән дә ким булмаска тиеш.

2.3. Палаткалы лагерьда профильле смена – каникуллар вакытында, укучылар һәм тәрбияләнүчеләр тәүлек буе кыр шартларында була торган, иҗади сәләтле балалар белән (яшь техниклар, туган якны өйрәнүче туристлар, экологлар, спортчылар, математиклар, филологлар, журналистлар, коткаручылар, диңгезчеләр, автомобильчеләр, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы сменалары) белем бирү һәм сәламәтләндерү эшчәнлегенең формасы. Сменаның палаткалы лагерьда тәкъдим ителгән дәвамлылыгы 5-21 көн. Палаткалы лагерьда сменалар 7 көннән артык вакытка оештырылганда, балаларга юыну шартлары булдырылырга тиеш.

2.4. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге ял лагерендагы смена – бу каникул чорында белем бирү оешмалары тарафыннан нигездә укучылар көндезге вакытта булган һәм аларны тукландыру мәҗбүри оештырылган, белем бирү оешмасы базасында үткәрелә торган сәламәтләндерү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Смена дәвамлылыгы каникулның дәвамлылыгы белән билгеләнә һәм җәйге каникуллар чорында 21 календарь көннән дә ким түгел, көзен, кышын һәм язын – 7 эш көненнән дә ким түгел.

2.5. Ял һәм хезмәт лагеренда смена – бу каникул чорында сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы, нигездә, гомуми белем бирү оешмалары базасында көндезге вакытта һәм туклану белән тәэмин итеп үткәрелә. Сменаның дәвамлылыгы – 24 календарь көннән дә артык түгел.

2.6. Лагерьларда отрядлар балаларның яшен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып туплана. Отрядларның саны лагерьлар төзелеше, аларны карап тоту һәм эш режимын оештыру буенча санитар-эпидемиологик таләпләр билгеләнгән нормативлар нигезендә билгеләнә.

2.7. Сменаны үткәрү сроклары сменаны оештыручы тарафыннан билгеләнә.

## 3. Балалар һәм яшьләрнең ял кампанияләрендә катнашучылар

3.1. Балалар һәм яшьләрнең ялы кампанияләрендә 4 яшьтән алып 17 яшькәчә балалар һәм 14 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшьләр катнаша.

3.2. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге категория балалар арасында гамәлгә ашырыла:

гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары;

авыр тормыш хәлендә булган балалар;

муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары;

муниципаль районның коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешмалары (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) хезмәткәрләренең балалары;

иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм яшьләр, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең активы әгъзалары, өстәмә белем бирү учреждениеләренең укучылары;

балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә исәптә торучы балалар, девиант тәртипле балалар.

## 4. Балалар һәм яшьләр ялын оештыручылар

4.1. Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге шәһәр яны ял лагерында профильле смена, палаткалы лагерьда профильле смена оештыра, шулай ук авыр тормыш хәлендә калган, хроник авырулардан интегүче балаларның, «Кайгырту» социаль приютында тәрбияләнүчеләрнең, күп балалы һәм аз керемле гаиләләрдәге балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыра.

4.2. «Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре, коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешма (муниципаль һәм дәүләт учреждениеләреннән тыш) хезмәткәрләре балаларының ялын Татарстан Республикасының шәһәр яны ял лагерьларында (шифаханә-курорт учреждениеләрендә), Татарстан Республикасының шәһәр яны ял лагерьларындагы профильле сменаларда, балаларга өстәмә белем бирүнең вакытлы (кыска вакытлы) берләшмәләрендә оештыра, җәйге каникуллар вакытында балигъ булмаган балаларны (мәктәп укучыларын) вакытлыча эшкә урнаштыру, белем бирү оешмалары оештырган көндезге ял лагерьларында балаларның көндезге ялын тәэмин итүне, хезмәт һәм ял лагерьларында ял итүне, көндезге ял итү лагерьларында балалар белән эшләү өчен кадрлар әзерләүне оештыра.

4.3. «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» санаторий учреждениеләрендә балаларны яңадан дәвалау белән бергә ял итү һәм сәламәтләндерүен оештыра, балаларны савыктыру учреждениеләрен медицина кадрлары белән тәэмин итә (килешү нигезендә), вакытлыча эшкә урнашканда балигъ булмаганнарга профилактик медицина тикшерүләре үткәрүне тәэмин итә.

4.4. «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган балаларны, авыр тормыш хәлендә булган балигъ булмаганнар арасында күзәтүчесезлекне, җинаятьчелекне кисәтү максатыннан, укудан буш вакытларында вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыра.

4.5. Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге җәйге кампания вакытында хокук саклау тәртибен оештыра.

4.6. Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге ял легерьлары базасында кызыксыну буенча берләшмәләрнең эшен оештыра.

4.7. «Татмедиа» ААҖ филиалы Алексеевск районының «Таң» газетасы «Таң» район газетасы битләрендә Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял итү мәсьәләләрен чагылдыра.

## 5. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслау тәртибе

5.1. Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслау түбәндәге чыганаклардан:

федераль бюджет акчалары;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

Алексеевск муниципаль районы бюджеты акчалары;

оешма һәм предприятиеләрдән кергән акчалар;

ата-аналардан кергән акчалар;

гамәлдәге законнарда каралган башка чыганаклар.

5.2. Балалар һәм яшьләр ялын оештыруны финанслау Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләр ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары чикләрендә гамәлгә ашырыла. Чираттагы финанс елына Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар балалар һәм яшьләрнең ял итү компаниясендә катнашучы бер кешегә исәпләнгән ялын оештыру формалары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

5.3. Авыр тормыш хәлендә булган балаларның, балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә исәптә торучы балаларның, девиант тәртипле балаларның ялын оештыру, хезмәт һәм ял лагерьларындагы сменаларда Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслана.

5.4. Татарстан Республикасының «Сәләт» балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары слетын оештыру Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына финанслана.

5.5. Өлешләп катнашу тәртибендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары хисабына балалар һәм яшьләр ялын оештыру финанслана:

иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар һәм яшьләрнең, актив әгъзаларының, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең ялы шәһәр читендәге ял лагерьларының һәм палаткалы лагерьларның профильле сменаларында;

белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге ял лагерьларында гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларының ялы;

шәһәр яны ял лагерьларында дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешма (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләре балаларының ялы.

5.6. Балалар һәм яшьләрнең ялын, аларны савыктыруны һәм эш белән тәэмин итүне финанслауда өлешләп катнашу күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән тәшкил итә:

Шәһәр читендәге ял лагерьларында һәм палаткалы лагерьлардагы профильле сменалар өчен, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен, белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге ял лагерендагы гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары өчен, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары өчен шәһәр читендәге ял лагерындагы сменалар өчен чираттагы финанс елына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарның 85% ы.

Шәһәр читендәге ял лагерьларында коммерцияле һәм коммерцияле булмаган оешма (дәүләт яки муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балаларына оештырылган сменалар өчен чираттагы финанс елына балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарның 42,5% ы.

## 6. Балалар һәм яшүсмерләрне ял иттерү һәм сәламәтләндерү өчен ата-аналар түләве күләмен билгеләү тәртибе

6.1. Сәламәтләндерү учреждениеләрендә балалар һәм яшьләрнең ялы өчен ата-аналар түләвенең күләме балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар буеча 15 процентттан да ким булмаган күләмдә билгеләнә, тик ял төрләренә карап юлламаның фактик бәясеннән 50 процентттан да артмаска тиеш.

6.2. Учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан күрсәтелгән хезмәтләрнең үзкыйммәтенә тигез чыгымнарны чагылдыручы юлламаның бәясе билгеләнә. Чыгымнар нормативлары реаль чыгымнарны чагылдырмаса, юлламаның факттагы бәясе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар өлеше арасындагы аерма ата-аналар (яки законлы вәкилләр), оешмалар тарафыннан түләнә.

6.3. Балаларны сәламәтләндерү учреждениеләрендә ял итү һәм сәламәтләндерү өчен Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге тарафыннан бирелүче юлламалар буенча ата-аналар түләве алынмый:

авыр тормыш хәлендә булган балаларга,

балигъ булмаганнар эшләре буенча комиссиядә исәптә торучы балаларга, девиант тәртипле балаларга.

6.4. Хезмәт һәм ял лагерьларында ял иткән өчен ата-аналар түләве.

6.5. Татарстан Республикасының «Сәләт» балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары слетында катнашучылардан түләү алынмый.

## 7. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге ял лагерьларында балаларның ял сменаларын оештыру тәртибе

7.1. Белем бирү оешмасы оештырган көндезге ял лагерена гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары ата-аналарының (законлы вәкилләренең) гаризасы нигезендә җибәрелә.

7.2. Ата-аналарның гаризасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча укучы белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесенә бирелә.

7.3. Гомуми белем бирү учреждениесе ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризалары нигезендә гомуми белем бирү учреждениесенең балалар исемлеген төзи һәм аны «Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ тәкъдим итә.

7.4. Җыелма исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме

балның туган көне, ае, туган елы, җенесе

ата-ананың (законлы вәкилнең) эш урыны

бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме

бала укый торган сыйныф.

7.5. «Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ җәйге сәламәтләндерү кампаниясе өчен 30 календарь көнгә кадәр һәм кышкы сәламәтләндерү кампаниясе өчен 15 календарь көнгә кадәр, гомуми белем бирү учреждениеләре балалары исемлеге нигезендә, муниципаль район балаларының җыелма исемлеген һәм белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге тору лагерьларында аларның ялын оештыру планын төзи.

7.6. Белем бирү оешмасы оештырган лагерьларда балаларның көндезге ялларын оештыру планы, Чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган мәгариф оешмалары, муниципаль район оештырган лагерьларда балаларның ялын һәм аларны сәламәтләндерүне оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары чикләрендә, формалаштырыла һәм ул үз эченә ала:

базасында көндезге ял лагерьлары оештырылачак гомуми белем бирү учреждениеләренең исемнәрен;

гомуми белем бирү учреждениеләрендә оештырылган көндезге ял лагерьларындагы урыннар санын;

гомуми белем бирү учреждениеләрендәге көндезге ял лагерьларының сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгын;

балаларны базасында көндезге ял лагерьлары һәм сменалар оештырылачак гомуми белем бирү учреждениеләре буенча бүлү.

7.7. Көндезге ял лагерьларда балаларның ялын оештыру планы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

## 8. Ял һәм хезмәт лагеренда сменаны оештыру тәртибе

8.1. Хезмәт һәм ял лагерена гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары ата-аналарының (законлы вәкилләренең) гаризасы нигезендә җибәрелә.

8.2. Ата-аналарның гаризасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча укучы белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесенә бирелә.

8.3. Гомуми белем бирү учреждениесе ата-аналарның (законлы вәкилләр) гаризалары нигезендә гомуми белем бирү учреждениесенең балалар исемлеген төзи һәм аны «Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге»МКУ тәкъдим итә.

8.4. Җыелма исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме

баланың туган көне, ае, елы, җенесе

ата-ананың (законлы вәкилнең) эш урыны

бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме

бала укый торган сыйныф.

8.5. «Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ гомуми белем бирү учреждениеләре балалары исемлекләре нигезендә җәйге сәламәтләндерү кампаниясе өчен 30 календарь көнгә кадәр муниципаль район

балаларының җыелма исемлеген, хезмәт һәм ял лагерьларында аларның ялын һәм мәшгульлеген оештыру планын төзи.

8.6. Хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын һәм мәшгульлеген оештыру планы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган муниципаль районның хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын һәм мәшгульлеген оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативлары чикләрендә чираттагы финанс елына формалаша һәм үз эченә ала:

хезмәт һәм ял лагерьлары оештырылачак гомуми белем бирү учреждениеләре исемнәре;

гомуми белем бирү учреждениеләрендә оештырылган хезмәт һәм ял лагерьларындагы урыннар саны;

гомуми белем бирү учреждениеләрендә оештырылган хезмәт һәм ял лагерьларындагы сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;

балаларны базасында ял һәм хезмәт лагерьлары оештырылачак гомуми белем бирү учреждениеләре буенча бүлү.

8.7. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән балаларның хезмәт һәм ял лагерьларында ялын һәм мәшгульлеген оештыру планы раслана.

## 9. Авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын оештыру тәртибе

9.1. Авыр тормыш хәлендә калган балалар Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә бирелгән ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә сәламәтләндерү учреждениеләренә җибәрелә.

9.2. Авыр тормыш хәлендә булган балаларга түбәндәгеләр керә:

җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән җан башына яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаилә балалары, шул исәптән әти-әниләре пенсионерлар яки инвалидлар булган күп балалы, тулы булмаган гаиләләр;

социаль яктан куркыныч хәлдә булган балалар (тормышлары яки сәламәтлекләре өчен куркыныч булган яки балаларны тәрбияләү һәм карап тоту таләпләренә җавап бирми торган шартлар);

социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган учреждениеләрдә тәрбияләнүчеләр.

9.3. Ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы расланган форма буенча бирелә.

9.4. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге авыр тормыш хәлендә булган, сәламәтләндерү учреждениеләренә җибәрелә торган балалар исемлеген төзи, күрсәтелгән исемлекне Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт Министрлыгына тапшыра.

9.5. Исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкилнең, балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешма җитәкчесенең) фамилиясе, исеме, атасының исеме

икенче ата-ананың фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр икенче ата-ана булса);

ата аналарының (законлы вәкилләренең) эш урыны (әгәр булса)

баланың туган көне, ае, елы, җенесе;

бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме;

авыр тормыш хәлендә булган балалар категориясе;

бала укый торган сыйныф;

баланың сәламәтләндерү учреждениесендә булачак ае.

9.6. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге авыр тормыш хәлендә булган балаларның җыелма исемлеге нигезендә сәламәтләндерү учреждениеләрендә аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планын формалаштыра.

## 10. Шәһәр читендәге лагерьларның профильле сменаларында, палаткалы лагерьларда балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе

10.1. Шәһәр читендәге лагерьларның, палатка тибындагы лагерьларның профильле сменаларында катнашу өчен гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр җибәрелә.

10.2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары ата ананың (законлы вәкилләрнең) яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә – палаткалы сменаны оештыручыга тапшырылган гаризасы нигезендә палатка тибындагы лагерьларга җибәрелә. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары шәһәр читендәге лагерьларның профильле сменаларына укучы белем ала торган гомуми белем бирү учреждениесенә бирелгән ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) гаризасы нигезендә җибәрелә, анда укучы белем ала. Гомуми белем бирү учреждениесе шәһәр читендәге лагерьларның профильле сменаларына җибәрелә торган балалар исемлеген төзи, җәйге сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы әлеге исемлекне муниципаль район Башкарма комитетының мәгариф бүлегенә тапшыра.

10.3. Ата-аналарның гаризалары җәйге яки кышкы сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы сменаларны оештыручылар раслаган форма буенча бирелә.

10.4.Сменаларны оештыручылар шәһәр яны лагерьларына, палаткалы лагерьларга җибәрелә торган профильле сменада катнашучы балаларның җыелма исемлеген формалаштыралар.

10.5.Профильле сменаның һәр катнашучысы буенча җыелма исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме

ата-аналарның (законлы вәкилләренең) фамилиясе, исеме, атасының исеме

ата-аналарның (законлы вәкилләренең) эш урыны

баланың туган көне, ае, елы,җенесе

бала укый торган гомуми белем бирү учреждениесенең исеме

сменада катнашучы балала йөри торган өстәмә белем бирү учреждениесенең, иҗтимагый оешманың, иҗтимагый яшьләр оешмасының исеме (әгәр бар икән)

баланың казанышлары яки иҗтимагый оешмалар яки берләшмәләрнең тәкъдимнәре

бала укый торган сыйныф

балаларның җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында шәһәр яны лагеренда, палаткалы лагерьда булачак ае

дәүләт (муниципаль) йөкләмәсе нигезендә профильле смена оештырылачак шәһәр читендәге лагерь, палатка тибындагы лагерь исеме яки ачык конкурс нәтиҗәләре буенча шәһәр читендәге лагерьларда, палаткалы лагерьларда балаларның ялын оештыруга юлламалар сатып алу кирәклеге турында сылтама.

10.6. Профильле сменаларны оештыручылар җәйге яки кышкы сәламәтләндерү кампаниясе башланганчы профильле сменаларда катнашучы балаларның җыелма исемлеге нигезендә шәһәр яны лагерьларының, палатка тибындагы лагерьларның профильле сменаларында аларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планын формалаштыра.

10.7. Профильле сменаларда катнашучы балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планы үз эченә алырга тиеш:

балалар – профильле сменаларның катнашучылары җибәрелә торган шәһәр читендәге лагерьларының, палатка тибындагы лагерьларның исеме, аларда урыннар һәм сменалар саны;

шәһәр яны лагерьларындагы, палаткалы лагерьлардагы сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы.

10.8. Профильле сменаларда катнашучы балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

## 11. Хисап бирү тәртибе

11.1. Балалар һәм яшьләр ялын оештыручыларга Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының «Җәй» республика үзәге дәүләт бюджет учреждениесенә тәкъдим итәргә:

2019 елның 1 маена кадәр – барлык типтагы лагерьларны ачу графикларын;

2019 елның мартыннан декабренә кадәр, лагерьга урнашканнан соң 3 көн эчендә – оператив мәгълүмат, һәм ай саен 25 числога кадәр – балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча финанс хисаплылыгын.

11.2. Балалар һәм яшьләр ялын оештыручыларга төзелгән шартнамәләр һәм муниципаль контрактлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын куллану турындагы хисапларны вакытында тапшыруны тәэмин итәргә.

**Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче** **Г.А. Юсупова**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
04.03.2019 № 104
карарына 3 номерлы кушымта

**Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район комиссиясе турында нигезләмә**

1. Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләр ялын оештыру буенча район комиссиясе (алга таба – Комиссия) балалар һәм яшьләр ялын оештыру максатларында төзелә һәм Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының координацияләүче органы булып тора.

2. Комиссиягә рәис җитәкчелек итә, аның урынбасары була. Комиссия составына кызыксынучы ведомство һәм оешма вәкилләре керә.

3. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге законнарга һәм әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

4. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

балалар һәм яшьләр ялын әзерләү һәм оештыру буенча барлык милек формасындагы ведомстволар, төрле фондлар, акционерлык җәмгыятьләре, предприятиеләр һәм берләшмәләр, иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомстволар, оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлеген анализлау, комиссия утырышларында аларның хисапларын тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм финанслау мәсьәләләрен карау;

балалар һәм яшьләрнең ял итү программаларын тормышка ашыруны контрольдә тоту.

5. Комиссия хокуклы:

Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетына балалар һәм яшьләр ялын оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерләргә һәм кертергә;

балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалардан мәгълүмат соратып алырга;

балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын үтәүне контрольдә тотарга;

Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ял программасына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында Башкарма комитетка тәкъдимнәр кертергә.

6. Комиссия утырышлары кирәк булган саен үткәрелә, әмма айга бер тапкырдан да ким түгел.

7. Компетенцияләре кысаларында кабул ителгән Комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия.

8. Комиссия карарлары утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Комиссия карарларына суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

9. Утырыш беркетмәләре комиссия рәисе тарафыннан имзалана.

**Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче** **Г.А. Юсупова**

Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
04.03.2019 № 104
карарына 4 номерлы кушымта

**Алексеевск муниципаль районында балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча район комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Кадыров Наил Камил улы | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе |
| Чурин Николай Пётр улы | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Рыдаев Вячеслав Юрий улы | Алексеевск муниципаль районының «Балалар һәм яшүсмерләр туризмы һәм экскурсияләр станциясе» өстәмә белем бирүче муниципаль учреждение директоры, комиссия сәркатибе. |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Тимонина Нина Юрий кызы | «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры (килешү буенча) |
| Леденцов Олег Николай улы | Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе |
| Гиләҗев Дамир Әмир улы | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ җитәкчесе |
| Ещев Олег Леонид улы | ТР буенча Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Алексеевск һәм Балык Бистәсе муниципаль районнарының районара күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге җитәкчесе (килешү буенча) |
| Кәбиров Рөстәм Рәшит улы | Алексеевск муниципаль районы балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе муниципаль белем бирү учреждениесе директоры |
| Сөләйманов Рифкат Бари улы | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Монина Ириа Юрий кызы | «Татмедиа» ААЖ филиалы директоры - Алексеевск районы «Таң» газетасының баш мөхәррире» (килешү буенча) |
| Мишечкин Владимир Геннадий улы | ПЧС ФГКУ «ТР буенча 7 нче ФПС отряды» башлыгы (килешү буенча) |
| Яковлев Вячеслав Анатолий улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Соловьёв Артур Геннадий улы | Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы |
| Фәхретдинов Илдар Азат улы | «Алексеевск үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы (килешү буенча); |
| Хөснетдинов Рөстәм Рафик улы | Татарстан Республикасы буенча «Роспотребнадзор» идарәсенең Чистай, Спас, Алексеевск һәм Яңа Чишмә районнарындагы территориаль бүлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча); |
| Хамзина Елена Александр кызы | ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Алексеевск районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Крохина Надежда Александр кызы | «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» МБУ җитәкчесе; |
| Фассахова Гөлсинә Гөмәр кызы | Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы " Балалар иҗаты үзәге» МБУ директоры |

**Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче** **Г.А. Юсупова**